ХӘРӘКӘТ БӘЯСЕ
Белгечләр әйтүенчә, 25–30 елдан соң гына электромобильләр саны углеводород ягучы автомобильләрдән күбрәк булачак
> 2

ВАТАН САКЧЫСЫ
Батырлык ордены белән бүләкләнгән якташыбыз Руслан Ханнановның тормыш сәхифәләре
> 3

АЧЫК ҺАВАДА
Болгарда узучы фестивальдә 50 меңләп кунак көтәләр
> 3

ХА-ХА-ХАНӘ
Булмас димә, кызык-мызык, фототөрткеләр биредә
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 100 (29067) | Шимбә | 15 июль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БЕР ТӨЧКЕРҮ ҖИТӘ

ИЛДӘ ТУБЕРКУЛЕЗ ЙОКТЫРУ ОЧРАКЛАРЫ АРТКАН

Россиянең 44 төбәгендә туберкулез белән авыручылар саны арткан. Роспотребнадзор идарәсе белгечләре шулай дип чаң суга. Рәсми саннардан аңлашылганча, узган ел илдә 100000 кешегә 31,11 туберкулез йоктыру очрагы туры килгән. Бер ел эчендә Белгород (232 очракка арткан), Воронеж (438 очрак), Кострома (108), Ростов (1089) өлкәләрендә әлеге чирне йоктыручылар саны аеруча арткан. Татарстанга бу куркыныч ни дәрәҗәдә яный?

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, Җир шарында ел саен якынча 9 миллион кешедә туберкулез ачыклана. Бу көн саен 5 мең кешедә әлеге мәкерле чир табыла дигән сүз. Ел саен аннан 2 миллионлап кешенең гомере өзелә.

Татарстанда да хәлләр мактанырлык түгел. Республика клиник туберкулезга каршы диспансерының баш табиб урынбасары Ленар Әхмәдуллин сүзләренә караганда, соңгы бер елда бездә дә әлеге чирне йоктыручылар саны арткан.

– 2000 елдан башлап республикада туберкулез йоктыручылар саны салмак рәвештә елдан-ел кимеп килә иде. Әмма узган ел Татарстанда әлеге чир белән авыручылар саны 7 процентка артты. Бу – алдагы ел белән чагыштырганда 59 кешегә күбрәк дигән сүз. Быелның алты ае нәтиҗәләре буенча да республикада туберкулез белән авыручылар узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 1,7 процентка (8 очракка) күбрәк теркәлде, – ди баш табиб урынбасары.

Ленар Әхмәдуллин фикеренчә, туберкулез йоктыру очраклары арту, иң беренче чиратта, коронавирус пандемиясенә бәйле. Хәтерләсәгез, илдә яңа вирус котырган чорда бу хакта Россиянең фтизиатрия буенча баш белгече Ирина Васильева да кисәткән иде.

– Коронавирус, иң беренче чиратта, иммунитетны какшатты. Ә бу, үз чиратында, безнең организмда йокымсырап яткан туберкулез таякчыкларының баш күтәрүенә китерә. Аннары коронавирус белән авырган күп кешенең үпкәләрендә эзләр калды. Бу үзгәрешләр аркасында үпкәнең сыгылмалылыгы югала, үпкә тукымаларының кан һәм һава әйләнеше начарлана. Андый кешеләрнең туберкулез йоктыру ихтималы зурая, – ди табиб. – 2020–2021 елдагы карантин чорында туберкулезны профилактика чаралары белән алдан ачыклау да кыенлашты. Узган елдан башлап бу чаралар кабат торгызылды. Бу, үз чиратында, элек күренмәгән авыруларны табарга ярдәм итте.

Алай да хәвефләнергә кирәкми, дип тынычландыра белгеч. Ник дигәндә, әлеге чирне ачыклау һәм дәвалау ышанычлы контрольдә. Бүген Татарстанда якынча 1,5 мең кеше туберкулездан дәвалана. Чирнең йогышлы формасы белән авыручылар шундук хастаханәгә салына. Авыру йогышлы булудан туктаганчы шунда дәвалана алар. Аннары табиблар контроле астында ял йортында яки өйдә торып дәваланып бетәләр. Туберкулез белән авырып терелүчеләр берничә ел дәвамында диспансерда исәптә тора.

Әлмәт үзәк район хастаханәсенең табиб-пульмонологы Рөстәм Насретдинов фикеренчә, туберкулез белән шаярырга ярамый. Ник дигәндә, ул беркемне дә аямый. ВИЧлы кешеләргә туберкулез эләктерү куркынычы 20–30 тапкыр күбрәк яный. Иммунитетны какшатучы авырулары булган, шикәр чиреннән интеккән, тәмәке тарту кебек начар гадәте булган кешеләр дә бу чиргә тизрәк бирешә.

– Туберкулез һава аша йога. Моның өчен авыру кешенең бер тапкыр төчкерүе дә җитә. Вакытында дәваланмаса, ул елына уртача 10–15 кешегә зыян салырга мөмкин. Туберкулез йоктырган кеше йөткергәндә, гадәттә, канлы какырык бүленеп чыга. Бу – әлеге чирне башкаларыннан аерып тора торган иң төп билгеләрнең берсе, – ди табиб. – Моннан тыш туберкулез йоктырган кешене хәлсезлек борчый, аның күкрәк читлеге авырта, ул тиз арада ябыга, төнлә тиргә батып уяна, тәнен бизгәк тотарга да мөмкин. Әлеге билгеләрнең берсе генә күзәтелсә дә, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Рөстәм Насретдинов балага манту ясатуга каршы булган ата-аналарны да җиде кат уйларга чакыра. «Туберкулез биш яшькә кадәрге балалар арасында бигрәк тә еш очрый. Үпкәләрдән тыш сабыйның үзәк нерв системасын, сөяк, бөерләрен дә зарарларга мөмкин ул», – дип кисәтә табиб.

Авырудан саклану өчен белгечләр гади генә кагыйдәне истә тотарга куша. Ленар Әхмәдуллин сүзләренә караганда, моның өчен вакытында флюорография тикшерүе узарга кирәк.

– Сәламәт кеше – ике елга бер тапкыр, хроник чирләре булган кешеләр елга бер тапкыр флюорография узарга тиеш. Психик авырулар, ВИЧ-инфекцияле кешеләр, наркомания һәм эчкечелек белән мавыгучылар әлеге тикшеренүне елга ике мәртәбә үтәргә тиеш. Иң мөһиме – туберкулездан үлүчеләр һәм аның йогышлы формалары артмый. Вакытында табылган туберкулез дәвалауга бирешә, – ди баш табиб урынбасары.

Россиядә туберкулез белән авыручылар саны

(Роспотребнадзор идарәсеннән алынган мәгълүматлар)

2018 ел – **44,06***
2019 ел – **41,08**
2020 ел – **32,07**
2021 ел – **30,71**
2022 ел – **31,11**

**100000 кешегә туры килгән очрак*

Укытучыга – һәйкәл

Татарстанда алдагы ярты елда Укытучы һәм остаз елын үткәрүгә багышланган чаралар планы расланды. Бу хакта Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин имзалаган боерыкта әйтелә.

Чаралар исемлегендә яңа мәдәни һәм иҗтимагый киңлекләр булдыру каралган. Әйтик, ярты ел эчендә Татарстан мәгарифе музееен төзү, Укытучы һәйкәлен урнаштыру һәм сквер ачу, мәгариф системасы турында китаплар нәшер итү планлаштырыла. Моннан тыш, республикада XIII Халыкара укытучылар фестивале, «Буыннар диалогы» фестивале кебек чаралар узачак.

Әлеге вакыйгаларның нәтиҗәлелеге алдан билгеләнгән стандарт нигезендә бәяләнәчәк. Әйтик, узган ел белән чагыштырганда ведомство бүләкләре белән билгеләп үтелгән педагоглар саны – 20, уку йортларына җәлеп ителгән укытучылар саны 10 процентка артыр дип көтелә.

Бала акча эшли

Татарстанда беренче яртыеллыкта 7 меңнән артыграк үсмер эшкә урнаштырылган. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы хәбәренә караганда, җәйге каникул вакытында алар асылда төзекләндерү, яшелләндерү, яшелчә үстерү-карау, чистарту-җыештыру буенча вак-төяк эшләр башкара.

Министрлыкта әйтүләренчә, һәр җәйдә уртача 10 меңгә якын бала вакытлыча эшләп ала. Республикада узган елда каникул чорында 12,6 мең укучыга шундый мөмкинлек тудырылган. Мәшгульлек үзәкләре аша эшкә урнашучыларга аена 2,2 мең сум күләмендә матди ярдәм бирелә. Эш бирүчеләр исә аларга хезмәт хакының минималь күләменнән ким булмаган акча түли.

Үсмерләр мәктәп, спорт мәйданчыкларын төзекләндерүчеләргә, шәһәр-авылларны яшелләндерүчеләргә булыша. Моннан тыш алар су буйларын, урманнарны чүп-чардан чистарта, яшелчә утырта, үстерә, чүбен утый, уңышын җыя.

Фондка мөрәҗәгать ит!

«Ватанны саклаучылар» фондының Татарстандагы филиалында (Казанда урнашкан) махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү мәсьәләләре буенча шәхсән кабул итүләр үткәреләчәк.

Сишәмбе – 18 июльдә Россия Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының Татарстандагы бүлеге җитәкчесе Эдуард Вафин халыкны кабул итәчәк. Ул социаль түләүләр, пенсия белән тәэмин итү, ярдәм, техник реабилитация чаралары белән тәэмин итү, шифаханә-курорт шартларында сәламәтлекне ныгыту турында сорауларга җавап бирәчәк.

Чәршәмбе – 19 июльдә исә Татарстанда Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская кабул итү уздыра.

Кабул итүләр фонд филиалында (Казан ш., Ямашев пр., 1) үткәрелә. Телефон аша (+7(843) 598-33-55) алдан язылып куярга кирәк.

Вазгыять һәм гамәл

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ:

«ТАТАРСТАНГА ЫШАНЫЧ ЗУР»

РЕСПУБЛИКА РӘИСЕ ОТР ТЕЛЕКАНАЛЫНА ИНТЕРВЬЮ БИРДЕ

Ярты сәгать дәвам иткән әңгәмә барышында республиканың үткәне, бүгенгесе һәм иртәгәсенә дә тукталдылар. Сөйләшү барышында яңгыраган төп фикерләрне сезгә дә тәкъдим итәбез.

Көнчыгыш белән элемтәләр турында

Татарстан географик яктан, хәер, алай гына түгел, геологик яктан да мөһим җирдә урнашкан. Элгәре яшәүчеләр, ил җитәкчелеге юкка гына Казан университетында тәүге Көнчыгыш юнәлешен ачу карарын кабул итмәгән. Бирәдә белгечләр әзерләү үзәген дә оештырганнар. Илебез өчен Көнчыгыш белән элемтәләр урнаштыру һәрвакыт мөһим булып саналган. Бүген исә бу эшнең әһәмияте тагын да артты. Чөнки элеккеге хезмәттәшләребез безнең белән дуслыкны өзде. Шуңа күрә без гарәп дөньясы, Көнчыгыш, Кытайга таба тагын да җитдирәк карый башладык. 2003 елда ил Президенты Владимир Путин Россияне Ислам хезмәттәшлеге оешмасына күзәтүче итеп алырга тәкъдим итте. Быел бу эшкә егерме ел. Үзебез үк күреп торабыз: хәзерге шартларда теге якта калган кебек булсалар да, Ислам хезмәттәшлеге оешмасына керүче хезмәттәшләребезнең мәсьәләгә үз карашы бар һәм бер генә элемтә дә өзелмәде. Моны үзебез үткәргән форумнардан, яңа элемтәләрдән чыгып та әйтә алабыз. Безнең сәүдә-икътисадый мөнәсәбәтләргә игътибар итсәгез дә, алар Фарсы култыгы, Көнчыгышка таба борылды. Татарстанда булган мөмкинлекләр ил мәнфәгатьләрен алга этәрү өчен файдалы булачак дип уйлыйм. Көнчыгыш та безнең белән кызыксына.

> Татарстан күп кенә күрсәткечләр буенча алдынгы урында. Бу исә билгеле бер күләмдә психологик басым да ясый. Башкалардан калышасы килми. Ә моның өчен тизрәк хәрәкәтләнергә, тизрәк йөгерергә кирәк.

Күпмилләтлелек турында

Илдә тынычлыкны сакларга төрле милләт һәм дин вәкилләренең үзара бергә яшәү тәҗрибәсе ярдәм итә. Безне генә алсак та, ислам һәм православие бар. Күрәсең, борынгы бабаларыбыз бик акыллы, зирәк булганнардыр, алар үз диннәрен, телләрен, мәдәниятен саклап калган. Мин моны илебезнең, Татарстанның зур казанышы дип саныйм. Казан Кремлендә православие чиркәве дә, мәчет тә бар. Гомумән, Татарстанда мондый урыннар бик күп. Моны, барыннан да бигрәк, өлкән буын тәрбиясе дип саныйм. Бу буыннан буынга күчә. Без дә әлеге мәсьәләгә бик игътибарлы булырга тырышабыз. Республикада милләтара һәм динара каршылыклар юк. Традицион тарихи кыйммәтләрне бер онытып бетергәч, аларны яңадан кайтару кыен. Ә без аны саклап кала алдык. Бу исә Җир йөзендәге тотрыклылыкның нигезе булып тора. Уртак йортыбыз безне әнә шулай яшәргә өйрәтте. Башкача була да алмый. Ничек кенә булмасын, дөньяда әнә шул татулыкны җимерергә теләүчеләр дә бар.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Виталий МУТКО, ДОМ.РФ генераль директоры, Россиянең элеккеге спорт министры:

Халыкара кампуслар, үзәкләр төзү турында күп сөйлибез. Барысына да әйтәм: «Казанга барып тәҗрибә алыгыз». Биредә иртәгә үк халыкара дәрәҗәдәге теләсә нинди чара уздырып була. Оештыру эшләре әнә шул дәрәҗәдә җайга салынган. Универсиада аркасында республика кыйммәтле оештыру тәҗрибәсе туплады һәм ил генә түгел, бөтен дөньяда үзен спорт башкаласы итеп танытты.

ТАТАРСТАНДА – СӨТЧЕЛЕК

13 июльдә Татарстанда 4611,9 тонна сөт савып алынган.

ИҢ КҮП СӨТ САВЫЛГАН РАЙОННАР

	Район	Савылган сөт, т	Бер сыерга, кг
1	Кукмара	421,4	26,6
2	Әтнә	345,7	31,5
3	Балтач	344,8	25,3
4	Саба	303,5	27,9
5	Мамадыш	234,1	28,5
6	Арча	209,6	22,6
7	Актаныш	208,8	20,8
8	Әлки	201,5	18
9	Азнакай	197,6	19,7
10	Минзәлә	149,3	26,2
	Татарстан буенча	**4611,9**	**21,4**

14 июльгә Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары

Куркыныч кимегән

Быелның беренче 6 аенда республикада кеше үлеменә китергән юл һәлакәтләре саны кимегән. Бу хакта юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Хөкүмәт комиссиясенең күчмә утырышында әйттеләр. Утырышны Премьер-министр урынбасары, комиссия рәисе урынбасары Шамил Гафаров уздырды.

6 айда республика юлларында 1510 авария булган. Аларда 114 кешенең гомере өзелгән, тагын 1826сы имгәнгән. Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда аварияләр 43кә арткан, ә һәлак булучылар 14 кешегә, имгәнүчеләр 8гә кимегән.

Акылга утырталар

Суд приставлары беренче яртыеллыкта Татарстанда торак-коммуналь хезмәтләр өчен бурычлы кешеләрдән 375,5 миллион сумлык әҗәтләрен түләткән. Республика суд приставлары идарәсе матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, мондый ваемсызларга еш кына мәҗбүриләү чаралары кулланырга туры килә. Шундый иң нәтиҗәле чараларның берсе – мөлкәткә арест салу. Мисалга, Казанда яшәүче бер ир-атның идарәче компаниягә 200 мең сумга якын бурычы җыелган. Пристав аның BMW машинасы барлыгын ачыклаган. Шуннан ул идарәче компания вәкиле белән автомобильгә арест салып, аны коммуналь хезмәт күрсәтүчеләрнең стоянкасына урнаштырган.

Бурычлы ир, машинасын алып китүгә үк, бөтен бурычын түләгән.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Озын-озак юл

Бер уйласаң, рәхәт заманда яшибез. Эшкә машинада барышлы. Югары катка лифт күтәрә. Электрга көйләнгән көнкүреш техникасы өйдәге эшнең олы өлешен эшләп тора. Халык әйтемендәгечә: «Ялкау ятыр – бәхете артыр», – дияр идең, саналган рәхәтлекләр бәхеткә бик үк бәйле түгел кебек. Бәхет – анысы күңел халәте. 240 ел элек тә, ат җигеп яисә атланып йөргәндә, машина түгел, паровозлар да күренмәгән, кораблар җил көчен файдаланган, электр дигән хикмәтнең исеме дә ишетелмәгән чорларда да адәми затларның бәхете бүгенгедән артык ким булмагандыр.

Нәкъ 240 ел элек – 1783 елның 15 июлендә Клод Аббан дигән француз кешесе елгага үзе төзегән беренче пароходны төшерә. Һәм шуңа утырып ярты чакрым чамасы агымга каршы йөзеп бара. Әлбәттә инде, пар көче ярдәмендә. Яр буена җыелган, ишкәк белән җилкәннән башканы күрмәгән халык, гаҗәпләнүдән, озак вакыт авызын яба алмый тора…

Пар машинасының төп детальләре пешкәк белән терсәкле вал икәнен дә әйтсәк – мондый тандемны уйлап табу һәм куллана башлау кешелек өчен революцион казаныш булганлыгын искәртергә кирәктер. Пешкәк һәм терсәкле вал. Бүген Җир йөзе буйлап миллиардтан артык автомобиль чаба. Аларның һәрберсендә, зурдан алганда, шундый ук механизм: алюминий коелмасыннан эшләнгән пешкәкләр, алар белән шатун дигән деталь аша тоташкан, әйләнмә хәрәкәтне ахырда тәгәрмәчкә илтеп җиткерүче терсәкле вал. Аерма шунда: пар двигателендә пешкәкне кызган пар басымы хәрәкәткә китерсә, хәзер барысын да бензин яисә дизель ягулыгы янганда барлыкка килгән газ басымы эшли.

Бүген һәр кешенең дә диярлек капоты астында дистәләгән атны алыштырган эчке янулы двигатель. Газ педаленә ныграк баскан саен пешкәкләр күз иярмәс тизлектә алга-артка йөри – без мең төрле мәшәкатебезне үтәп, машинада җилдертәбез. Автомобиль моторының эш принцибын белсәң ярый, белмәсәң дә бәла түгел. Һәрхәлдә, аны аңлау өчен һич тә инженер булу кирәкми. Ә менә ябык пар казаны астына аның саен утын өстәп, шартламаса гына ярар иде, дип барган Аббан үз заманы өчен шактый гыйлемле инженер саналган, диләр.

Безгә рәхәтлек, тизлек алып килгән пешкәкле эчке янулы двигатель. Ул уңайлык кына түгел, шактый олы проблемалар да китерде. Чөнки техник алгарыш пар машинасында гына туктап калмады. Миллиардтан артып киткән автомобильләрнең һәрберсе олы аппетит белән углеводородлы ягулык (бензин, газ, солярка) «ашап» хәрәкәтләнә. Ул әле тагын күпләп кислород та ашый. Чөнки яну процессы кислородсыз бара алмый. Двигательләрнең һәрберсе шуларны тәмләп «ашый» да тышка, без яшәгән тирәлеккә сасы сөрем газы – углекислота чыгара. Яшәгән саен күбрәк чыгара. Кеше заты, акылына килеп, тулысынча электромобильләргә күчкәнче, гадәти транспорт чаралары ныклап кими башлаганчы шулай булачак. Белгечләр, 25–30 елдан соң гына электромобильләр саны углеводород ягучы автомобильләр санын узачак, ди. Тик ул чирек гасырны да үтәсе бар бит әле.

Сөрем әлегә безне тончыктырмады. Әмма углекислотаның башка әшәкелеген дә беләбез. Ул – парник эффекты тудыручы газ. Эчке янулы двигательләрдән тулысынча баш тартканчы шул парник эффекты аркасында пешеп, янып бетмәбезме? Рәхәтлек, уңайлыклар дия-дия, җирдәге бөтен тереклекне шул 25–30 елда көйдермәбезме? Сораулар әлегә ачык кала. Һәр рәхәтнең үз михнәте була, диләр бит. Без аны инде бүген үк ярыйсы сизәбез…

Техник прогресс шул дәрәҗәгә җитте, күпләп электромобильләр чыгара башлау бүген олы проблема түгел дә кебек. Инженер дипломлы кеше буларак шуны төгәл беләм: электр моторының иң катлаулысы да – эчке янулы двигательгә караганда хәтсезгә гадирәк җайланма. Ник алайса шушы көнгәчә ишегаллары, урамнар һаман да бензин ягучы, тирә-якка сасы ис бөркүче хәрәкәт чаралары белән тулы соң? Ник юлларда электромобильләр очрамый яисә шактый сирәк очрый?

Беренчедән, проблеманың бар тарафларда да бездәге кебек түгеллеге мәгълүм. Шул ук Кытай электромобильләрнең йөздән артык төрен чыгара, дип язалар. Электр машинасының электромотордан кала икенче төп элементы – күп энергия сыйдырышлы аккумулятор. «Технология караклары» саналган кытайлар, бернинди урлашуларсыз, нәкъ менә шуны үтә дә сыйфатлы итеп ясарга өйрәнгән. Күк асты иле юлларында бүген 14 миллион чамасы электромобиль чаба, диләр. Шактый олы сан булса да, халкы миллиард ярымнан кимрәк ил өчен ушкитмәле түгел. Икенчедән, автоҗитештерүчеләр халыкара оешмасы (OICA) мәгълүматларына караганда, узган 2022 елда дөньяда җәмгысы 232 миллион автомобиль сатылган булса, шуның 10 миллионнан аз гына артыгы – электромобильләр. Ягъни электромобиль экзотика булудан туктап барса да, миллиардлы гадәти машиналар армиясен алыштырудан әлегә ерак…

Эчке янулы двигатель куелган автомобильне нефть тудырды. Кешелеккә бер үк вакытта бүләк тә, җәза да булган чимал. XX гасыр буе барган, без техник прогресс дип атаган алгарышта ул чималны, аннан аерып алынган продуктларны ягып хәрәкәт итүче күптин-күп төрле транспорт чараларының, башка механизмнарның роле әйтеп бетергесез дәрәҗәдә зур булды. Эчке янулы двигатель автотранспортта гына кулланылмый. Алар корабларда да, тепловозларда, карьерларда эшләүче алагаем экскаваторларда да. Очкычлардагы реактив двигательләр керосин яга, винтлыларына бензинының иң чистасы – авиация бензины дигәне кирәк.

Углеводород ягучы котельныйлар кышын безнең өйләрне җылыта, газга яисә мазутка көйләнгән электр станцияләре электр тогы эшләп чыгара. Бөтен тормыш, бөтен икътисадның «кара алтын»га барып тоташуы нефть корпорацияләрен инде хәтсездән дөнья кендеге, Аллаһының кашка тәкәсе итте. Дөнья тулысынча электромобильләргә күчкән тәкъдирдә алар ул өстенлекне югалтачак. Нәкъ шушы хәл бүгенге нефть лоббиен, ягъни ул даирәнең электрлы транспортны җитештерүгә каршылыгын тудырды да. Алар үзләрендә булган йогынты һәм чутсыз акча ярдәмендә электромобиль ясаучылар тәгәрмәченә таякны аның саен тыгып кына тора. Андый хәрәкәт чарасында алар гомумән үзләренең әҗәлен күрә…

Пешкәк һәм терсәкле вал дәвере иртәме-соңмы тарихта калачак. Җир мае чыгару, аны куллану да нык кимеячәк. Болай да планетаны җитәрлек пычраттык инде. Акыл белән яшәргә өйрәнгәндә безгә нәкъ менә электр моторы, электромобиль ярдәм кулы сузачак.

НЕФТЬЧЕЛӘР ҖЫЕЛГАН ҖИРДӘ

Әлмәттә «кара алтын», яшьләрне эшкә җәлеп итү һәм аларны борчыган мәсьәләләр турында сөйләштеләр. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов нефть саммитын башлап җибәрде, Халыкара нефть-газ яшьләр форумында катнашты һәм дөньяга үз карашы булган егет-кызлар белән очрашты.

Быел саммит республикада нефть чыгару сәнәгатенең 80 еллыгына һәм Ромашкино нефть чыганагы ачылуның 75 еллыгына багышланган. Республика нефть компанияләре җитәкчеләре катнашында ел саен үткәрелүче әлеге чарага кадәр Рөстәм Миңнеханов күргәзмә дә карады. Анда Татарстан һәм Пермь сәнәгать тармагы оешмалары яңа эшләнмәләрен һәм технологияләрен тәкъдим итте.

Саммитның пленар утырышында 2050 елга кадәр чорда ил ягулык-энергетика комплексын үстерү турында сөйләштеләр.

– Республика икътисадын алсак, аның төп нигезен нефть сәнәгате тәшкил итә. Ул акрынлап нефть эшкәртү сәнәгатенә күчеп бара. Без 36 миллион тонна «кара алтын» чыгарабыз, шуның 22 миллион тоннадан да күбрәген үзебез эшкәртәбез. Татарстанда шин сәнәгате, нефть химиясе һәм биотехник юнәлешләр үсә, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ул билгеләп үткәнчә, бүгенге шартларда икътисад үсешендә кеше капиталы мөһим урын алып тора.

– Безнең көндәшлегебез кадрлар әзерләүгә бәйле, – диде Рәис. – Җитди белем бирү үзәкләре кирәк. Без бу мәсьәлә белән актив рәвештә шөгыльләнәбез. Әлмәт – нефть, Түбән Кама нефть химиясе үзәге булып тора. Моннан тыш, бүген илгә 140 меңгә якын IT белгеч җитми. Бу да – безнең игътибар үзәгендә. «WorldSkills»та зур тәҗрибә тупладык. Белгечләр әзерләүнең яңа стандартларын булдырырга кирәклеген аңладык. Республикада 45 ресурс үзәге гамәлдә. Безнең «Алабуга Политех» җитди проекты да бар. Бүген анда 1300 студент белем ала, ә 2025 елга кадәр әлеге сан 10 меңгә кадәр җитәчәк дип фаразлана. Сүз Татарстан егет-кызлары гына түгел, ә бөтен Россия, Үзәк Азия, Африка һәм Латин Америкасыннан килүчеләр турында да бара.

Бу хакта сөйләгәндә, Рөстәм Миңнеханов яшьләрне республикада, аерым алганда, Әлмәттә калдыру турында да әйтте.

– Яшьләргә мохит кирәк. Шәһәр яшәү өчен уңайлы булырга тиеш. Бу социаль-мәдәни, сәламәтлек саклау объектларына да, иҗтимагый киңлекләргә дә кагыла. Иң мөһиме – Әлмәт әйдәп баручы фәнни-белем бирү үзәге булырга тиеш. Хезмәт базарындагы тәкъдимнәрне дә күз уңыннан ычкындырырга ярамый. Теге яки бу белгечлекне аласың икән, синә эш тә булырга тиеш. Яхшы хезмәт хакы, карьера буенча югары күтәрелү мөмкинлеге. Болар барысы да мөһим. Киләчәгебез – яшьләр кулында.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, без бүген зур үзгәрешләр чорында яшибез.

– Киләчәктә энергиянең кайсы төрләренә ихтыяҗ зуррак булачак, базар ничек төзеләчәк – фаразлар төрле. Шунысын ышандырып әйтә алам: мондый нефть эшкәртү һәм нефть химиясе булганда, яңа технологияләр һәм материалларны кулланышка керткәндә без алга таба да көндәшлеккә сәләтле булачакбыз, – диде Рәис.

Саммит белән бер мәйданда яшьләр форумы да узды. Быел анда Россия һәм чит илләрдән 250гә якын яшь белгеч катнаша. Җыенда катнашучылар Рөстәм Миңнеханов белән дә аралашты.

Биредә үк яшьләр җыелган тагын бер мәйданда экология, белем бирүне үстерү һәм Татарстан тарихын саклау турында сөйләштеләр. Рәис эковолонтерлар, «PROинтерес» фестивале катнашучылары һәм «Тарихны Кешеләр Яза» проекты вәкилләре белән очрашты. Эковолонтерлар, мәсәлән, республика җитәкчесенә табигатькә сакчыл караш тәрбияләү турында сөйләде. «PROинтерес» фестивале кадрлар әзерләүгә багышланса, өченче проект, исеменнән үк аңлашылганча, тарихны саклауга багышланган. 2019 елдан бирле яшьләр 2,5 мең ветеран белән аралашып, аларның истәлекләрен мәңгеләштергән.

Тыйнак кунак

Безгә килүче мигрантларны республика мәдәнияте, анда яшәүче халыкларның традицияләре һәм йолалары белән таныштырырга кирәк. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Татарстан Халыклар дуслыгы йортында узган очрашуда шулай дип белдерде. Бу тынычлык өчен кирәк.

«Эш һәм тормыш алып бару өчен мигрантларны Татарстан кызыктыра. Республикага килүче чит ил кешеләренең күпчелеге Казанда кала, калганнары Чаллы, Әлмәт һәм Алабуга кебек шәһәрләргә юл тота. Безнең бурыч – республикага килүчеләрнең Татарстанга ничек җайлашуын, нәрсә белән шөгыльләнүен ачыклау. Дөньядагы вазгыять милләтләр, диннәр арасындагы мәсьәләләрне даими контрольдә тотарга мәҗбүр итә», – ди Фәрит Мөхәммәтшин.

Парламент башлыгы Татарстан халыклары Ассамблеясы эшенә аерым тукталды. Ул республикада үткәрелә торган зур этномәдәни чараларда актив катнашканнары өчен милли-мәдәни автономияләр (ММА) вәкилләренә рәхмәт белдерде. «Милли бәйрәмнәр безнең халыкларны берләштерә, мәдәният, традицияләр һәм йолалар белән таныштыра, бу – төп кыйммәтләр. Безнең бурыч республика тыныч яшәсен өчен Татарстанга килүче мигрантларда күпмилләтле халкыбызның бай мәдәниятенә карата хөрмәт уяту һәм аның белән таныштыру», – диде Фәрит Мөхәммәтшин һәм ММА башлыкларына республикага килгән кешеләр белән якынрак аралашырга кушты.

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, җәй башында республикада 87344 чит ил кешесе яшәгән. Күбесе эш эзләп килгән. Хәзерге вакытта Татарстанда 3387 предприятие, оешма һәм шәхси эшмәкәр чит ил кешесен эшкә яллаган. Шул исәптән 50сенең Россиягә кергәндә виза алу шарты булган илләрдән килгән кешеләрне эшләтү хокукы бар. Андыйларга эш рөхсәте бирелә. Быелның 5 аенда чит илдән килгән 225 кеше әнә шундый документ алган. Күбесе – Төркия, Кытай һәм Төрекмәнстан гражданнары. Алар нигездә төзелеш, эшкәртү сәнәгате, җәмәгать туклануы тармакларында эшли. Хәзерге вакытта Россиягә виза белән килгән барлыгы 577 кешенең эш рөхсәте бар. Ә узган елның шул чорында андыйлар 4201 булган.

Визасыз килү мөмкинлеге булган чит ил кешеләренә исә эшкә урнашу өчен махсус патент бирәләр. Мондый документка хәзерге вакытта 35135 кеше ия.

Партия күчтәнәче

tatarstan.ru

Татарстан башкаласыннан Луганск Халык Республикасының Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләренә гуманитар йөкнең чираттагысы китте. «Бердәм Россия» партиясе ярдәмендә җыелган 75 тонна йөкне дүрт фурага төяп озаттылар.

Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин волонтерлар һәм хәйрия акциясендә катнашучылар белән аралашты.

– Республиканың партия активы баштан ук мондый гуманитар акцияләргә кушылды. Без һәрвакыт иң элек Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләрендә яшәүчеләрдән үзләренә нәрсә кирәк икәнен белешәбез. Шуңа күрә аларга иң мөһим әйберләрне генә җибәрәбез. Бүгенге йөктә азык-төлек тә, электр приборлары, дарулар да бар, – диде парламент башлыгы.

Дәүләт Советы Рәисе әйткәнчә, республика җитәкчелеге һәм партия активы гуманитар йөкнең чын мәгънәсендә мохтаҗларга барып ирешүе өчен мөмкин булганның барысын да эшли. Парламент башлыгы билгеләп үткәнчә, хәзерге вакытта республиканың «бердәмроссиялеләре» Лисичанск һәм Рубежноеда яшәүче балалар өчен мәктәп кирәк-яраклары, дәфтәр, портфель, язу-сызу әйберләре җыя башлаган.

Фәрит Мөхәммәтшин Татарстан «бердәмроссиялеләре»нә, предприятиеләр һәм оешмалар, районнар җитәкчеләренә гуманитар миссияләрдә актив катнашкан өчен рәхмәт белдерде. Ул шулай ук республикада яшәүчеләргә дә бу эшкә битараф калмаулары өчен рәхмәт сүзләре ирештерде.

Быел «Бердәм Россия»нең төбәк бүлеге ярдәмендә җыелган алтынчы гуманитар колонна инде бу. Махсус хәрби операция башланганнан бирле партиянең Татарстандагы активистлары Луганск Халык Республикасына барлыгы 1327 тонна – 93 йөк машинасы гуманитар ярдәм җибәргән.

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ:

«ТАТАРСТАНГА ЫШАНЫЧ ЗУР»

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Икътисад турында

Болгавыр 1990 нчы елларда предприятиеләребезне саклап калдык, алай гына да түгел, үстерүгә ирештек. Бу хакта сөйләгәндә, без Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевкә бик рәхмәтле. Ул вакытта хакимияттә нәкъ менә аның командасы эшләде. Минтимер Шәймиев – тәҗрибәле җитәкче. Билгесезлек чорында, ул вакытта Татарстанны да сепаратистлар итеп күрсәтергә теләүчеләр булды, предприятиеләрне ябу турында уй да булмады. Алда торган төп бурыч – тотрыклылык һәм сәнәгать мөмкинлекләрен саклап калу. Хосусыйлаштыру башлангач, предприятиеләрне таратып бетермәү, бу эштә дәүләт катнашын саклап калу мөһим иде. Нәтиҗәсе күз алдында. Мин ул вакытта зур җитәкче түгел идем әле. Әмма аларның дәвамчысы булдым. Татарстан сайлаган юл бик дөрес булып чыкты. Без моның өчен Беренче Президентыбызга рәхмәтле. Минтимер Шәймиев бүген дә республика тормышында актив катнаша. Без сәнәгать мөмкинлекләрен, эш урыннарын, халыкның керемен саклап калдык. Бу ил өчен эшләнде. Бүген авиация заводы да, вертолет заводы да, дары заводы да стратегик предприятиеләр булып санала, алар оборонаны ныгытуга хезмәт итә. Шул ук «КАМАЗ»ны алыгыз. Хәтерләсәгез, завод банкротлыкка чыккан һәм аны сату мәсьәләсе көн кадагында иде. Әмма Минтимер Шәймиев җитәкчелеккә моны эшләргә ярамаганлыгын җиткерә алды. Без булганын саклап кына калмыйча, икътисадны җитди рәвештә үзгәртә алдык. Чималга бәйлелектән котылу өчен, эшкәртү куәтләрен арттырдык. Нефть сәнәгате түбән тәгәрәгән чорда тармак оешмаларына ярдәм чараларын булдырдык. Федераль һәм республика дәрәҗәсендә тиешле карарлар кабул ителде. Нефть эшкәртү комплексын төзедек, нефть химиясе предприятиеләрен киңәйттек, энергетика тармагында зур проектлар башлап җибәрдек. Болар барысы да бүгенге дәрәҗәгә күтәрелергә ярдәм итте. Күптән түгел генә Казанда Россия Премьер-министры Михаил Мишустин булып китте. Ул ни өчен безнең авиация заводына килде дип уйлыйсыз? Төп бурыч – илне гражданлык авиация судноларын белән тәэмин итү. Әйе, «Суперджет» проекты бар. Ул бик яхшы, әмма импортка туры килгән өлеше зур. Бүген импортны алмаштыру юнәлешендә эш алып барыла. Ил тарафыннан безгә елына егерме Ту-214 очкычы җитештерү бурычы куелды. Россия Президенты моны хуплады. Ни өчен нәкъ менә безгә куштылар? Белгәнегезчә, үз вакытында Казанда Ту-160 очкычын җитештерүне туктаттылар. Ил җитәкчелеге бу эшне яңадан торгызырга кушкач, республика заводы әлеге бурычны тиешенчә үти алды. Ягъни Татарстанга ышаныч зур. Кыска вакыт аралыгында елына егерме очкыч җыя башлау – катлаулы бурыч. Әмма без моңа ничек ирешергә икәнен аңлыйбыз. Ил җитәкчелеге, Хөкүмәт ышаныч күрсәтте. Шуңа күрә без моны башкарып чыгарга тиеш.

tatarstan.ru

М12 төзелеше турында

Безгә уңыш елмайды. Мәскәүгә кадәр югары тизлекле юл турында күптән хыяллана идек. М12 трассасыннан ил башкаласына 6,5 сәгатьтә барып җитеп булачак. Татарстан – сәнәгать төбәге, шуңа күрә безнең өчен транспорт артерияләре бик мөһим. Бу эштә Ил Хөкүмәтенең өлеше зур. Владимир Путин М12 проектын хуплады. Эшне Хөснуллин Марат Шакирҗан улы контрольдә тота. Юлның җиденче һәм сигезенче өлешләре Татарстан аша узачак. Без дә юлчыларга мөмкин кадәр ярдәм итәргә тырышабыз. Казанга кадәр юл декабрьдә ачылачак. Татарстанда стратегик әһәмияттәге ике күпер дә төзелә. Аларның берсе Идел аша салынса, икенчесе – Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узу юлындагы Чулман күпере. Киләчәктә юлны Башкортстанга кадәр киңәйтү дә күздә тотыла. Әлеге заманча транспорт коридоры безгә алга таба хәрәкәт итәргә булышачак.

Санкцияләр турында

Бу бик авырттыра. Укол ясаганда да авырта бит? Бер яктан, санкцияләр бик җитди һөҗүм булып тора, чөнки технологик җиһазландыру ягыннан чикләүләр бар. Без дустанә мөнәсәбәттә булмаган илләрдәге бик күп тәэмин итүчеләрне югалттык. Икенче яктан, башка юлларны таптык. Әйткәнемчә, республика икътисады былтыр да, быел да үсеш күрсәтә. Әмма санкцияләр безгә авырткан җирләребезне күрсәтте. Эшне үзгәртеп корырга туры килде. Түзәргә кирәкми. Бу – бүгенге чынбарлык. Шуңа күрә тәгаен чаралар күрергә кирәк. Әлеге эштә федераль үзәк тә бик нык ярдәм итә.

Яшьләрне читкә җибәрмәү турында

Тормыш сыйфаты шәһәрдә генә түгел, авылда да яхшы булырга тиеш. Татарстанда гамәлдә булган 44 республика программасы һәм илкүләм проектларның 25–27се тирәсе авыл җирлекләрен үстерүгә багышланган. Без салада яшәүчеләрнең хезмәт хакы лаеклы булсын өчен тырышабыз. Татарстан агломерацияләргә бүленгән. Мәсәлән, Кама аръягы агломерациясендәге «КАМАЗ»да, «Алабуга» махсус икътисадый зонасында, Түбән Камада белгечләргә сорау зур. Яшьләр үзе яшәгән җирлектән китә икән, кире әйләнеп кайтулары бик шикле. Шуңа күрә урыннарда яхшы белем бирү үзәкләре, иҗтимагый киңлекләр булдырабыз. Яшьләргә кая да булса барып кайтырга, спорт белән шөгыльләнергә шартлар кирәк. Әти-әниләргә исә белем бирү мәсьәләсе мөһим. Әлмәт нефть институтын гына барып күрегез. Стэнфорд бер читтә торсын. Чынлап әйтәм. Иннополис университеты да бик лаеклы. Шулай ук Түбән Камадагы химия институты буенча да зур эш алып барыла. Ул СИБУР белән берлектә оештырыла. Чаллыда исә «КАМАЗ» белән берлектә Югары техника мәктәбе төзеләчәк.

Туризм турында

Элек Казан оборона-сәнәгать комплексы булган гадәти совет шәһәре генә иде. Туризмны үстерүгә беренче җитди адым ул – шәһәрнең Меңьеллыгы. Федераль ярдәм белән каланы тәртипкә китердек. Киләсе адым – Универсиада үткәрү. Казан ямьләнде. Бу ике дата безгә яхшы башлангыч бирде. Шәһәрне уңайлы һәм матур итү юнәлешендә эшләдек: иҗтимагый киңлекләр, спорт корылмалары, транспорт һәм кунакчыллык инфраструктурасын үстердек. Универсиада бик күп яңа кунакханәләр төзүне, шулай ук инглиз теле белгечләре әзерләүне таләп итте. Татарстанның Беренче Президенты тарафыннан зур эш башкарылды. Үз вәкаләтләрен миңа тапшыргач, Минтимер Шәймиев ике зур тарихи объект – Зөя шәһәр-утравы һәм Изге Болгарга алынды. Менә шушы эшләр төбәкне генә түгел, безне дә үзгәртте. Без кунакчыллыкка өйрәндек. Былтыр Татарстанга 4 миллион турист килде. Быел да моннан кимен көтмибез.

ТАМЫР ЮГАЛМАСЫН ӨЧЕН

«ЯҢАРЫШ: ДАСТАННЫҢ ЗАМАНЧА УКЫЛЫШЫ» ФЕСТИВАЛЕ НИЛӘР ВӘГЪДӘ ИТӘ?

15–23 июль көннәрендә Болгарда «Яңарыш: дастанның заманча укылышы» фестивале узачак. Үз эченә әллә ничә чараны алган бу фестивальгә Татарстан Мәдәният министрлыгында зур өметләр баглыйлар һәм 50 меңләп кунак көтәләр. Аның әһәмияте нидә? Болгарга кадәр баргач, ниләр карап кайтырга?

Ачык һавада узачак зур фестиваль берничә юнәлешкә бүленгән. Театр сөючеләр Болгарда Якутия («Олонхо»), Карелия («Кулерво»), Кыргызстан («Монасчы»), Болгария («Кубрат хан») милли театрларының дастаннарга нигезләнгән спектакльләрен, ә 23 июльдә «Кара пулат» операсын тамаша кыла алачак. Сүз уңаеннан, «Кара пулат» узган ел тәүге тапкыр ачык һавада күрсәтелгән иде. Мондый форматка аны «Әкият» курчак театры сәнгать җитәкчесе Илгиз Зәйни яраклаштырып эшләде. «Бездәге кадәр фестиваль беркайда да юк. Һәр театрның үз фестивале бар. Инде биналарга гына сыеша алмагач, урамга чыктык», – диде ул фестиваль хакында.

Чараларга әйләнеп кайтыйк. Модага битараф булмаганнарны «Тормыш рәвеше – мәдәни код» этно-fashion фестиваленә – Россия төбәкләре һәм чит илләрдән килгән дизайнерларның эшләнмәләре белән танышырга чакырып калалар. Шунда ук фестиваль көннәрендә «Ага Базар» ярминкәсе дә узачак. Анда исә меңләп оста үз эшләнмәләрен тәкъдим итәчәк.

Бу гына җитмәсә, концерт карап кайтырга мөмкин. Алар да көн саен узачак. Сүз уңаеннан, фестивальнең ачылыш тантанасында Татарстанның атказанган артисты Илсөя Бәдретдинова да чыгыш ясаячак. Мәдәният министры Ирада Әюпова аны, «Кара пулат» операсындагы кызлар кебек көчле шәхес, дип атады. Юкка гына нәкъ менә ул чыгыш ясамый, ягъни.

Билгеле, бу фестивальне киң җәмәгатьчелек өчен кызыклы итәргә тырышсалар да, аны чираттагы күңел ачтыру чарасы буларак кабул итәргә кирәкми. Аның оештырылу урыны итеп Болгар да юкка гына сайланмаган. Ирада Әюпова аның әһәмияте турында менә нәрсә диде:

– Болгарда узачак фестиваль безгә маңкортка әйләнмәс өчен кирәк. Без үзебезнең кайдан чыкканыбызны, тамырларыбызны белеп яшәргә тиеш, – диде ул чарага багышланган матбугат очрашуында. – Бу фестиваль буыннар алмашы турында уйланыр өчен дә этәргеч булсын иде. Тузганак булу җайлы – өрдең дә очып китте. Әмма тузганакның да тамыры була.

«Яңарыш…» фестивале кысасындагы тагын бер мөһим чара – театраль лаборатория. Казан һәм ГИТИС студентлары мәртәбәле режиссер белән бергә Чыңгыз Айтматовның «Мәңгелек буран» һәм Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрләренең эскизларын зур сәхнәгә чыгарачак. Бу ике әсәр юкка сайланмаган. Мәдәният министры аңлатуынча, «Мәңгелек буран» янә бер кат тамырлар белән элемтә югалу куркынычы турында кисәтсә, «Кыйссаи Йосыф» үз эченә халкыбызның рухи байлыгын сыйдырган.

Фестиваль кысасында Казан Кремлендә «Мирас һәм традицияләр» күргәзмәсе дә эшләячәк. Монда рәссамнар һәм осталар иҗат җимешләрен тәкъдим итеп, килгән кунаклар белән аралашачак. Оештыручылар, фестиваль кысасындагы барлык чараларга да керү бушлай, дип вәгъдә итә.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

УЛ БАШКАЧА БУЛДЫРА АЛМАС ИДЕ…

Ватан хакына

Бу сүзләр – махсус хәрби операциядә һәлак булган, үлгәннән соң Батырлык ордены белән бүләкләнгән якташыбыз Руслан Ханнанов турында. Хәләл җефете Марина да, хезмәттәшләре дә бу батыр егетебез турында бары тик шулай гына уйлый.

Безнең өчен исән

– Бүген Русланны гел искә төшереп, аның белән бергә булган көннәрне уйлап йөрү, бер яктан, авыр да кебек. Әмма икенче яктан караганда, без хәзер шул истәлекләр белән яшибез. Безнең өчен ул гел исән кебек. Руслан минем өчен – ир, балалар өчен әти генә түгел, якын дустыбыз да, киңәшчебез дә булды. Бервакыт шулай озак кына, бик авыр хәлдә хастаханәдә ятарга туры килгән иде. Бары тик Руслан ярдәме белән генә тернәкләндем кебек. Яныма килгәч, кулларымнан тота иде дә: «Кайгырма, мин янәшәңдә бит. Син – үзең дә көчле кеше. Менә күреп тор, савыгырсың», – дип күңелемне юата, билгесезлектән тартып чыгара, дәрт-дәрман өсти иде. Бик нык, кешелекле, ихлас, гадел булды ул. Сүзен әйткәнче, җиде кат уйлый торган гадәте бар иде. Башкаларга ярдәм итәргә дә ашкынып кына торды. Минем янга килгәч, палатада бергә яткан өлкән яшьтәге әбиләрнең дә гозерләрен үтәп китә иде. Үз әнием дә аны улы кебек якын күрде. Каенанам моннан дүрт ел элек бакыйлыкка күчте. Руслан үги әти белән үскән. Әнисенең яңа гаиләсендә туган энекәше Эдуардны бик яратты. «Бәләкәй вакытында күтәреп кенә йөрттем мин аны. Бервакыт шулай авырып китте дә, әле үзем дә бала гына идем, терелсен дип, шәһәрнең икенче башыннан кәҗә сөте ташыдым», – дип сөйли иде.

Ханнановларның шәхси архивыннан

Бик башлы да булган ул. Казанның Мәскәү районындагы 102 нче гимназияне дә, Танк училищесын да «5ле» билгеләренә генә тәмамлаган. Кечкенәдән хәрби булырга, Ватанны сакларга хыялланган.

Әти тәрбиясе

– Руслан гел гаилә дип яшәде. Вакыты булганда, балалар яныннан китмәде. Менә дигән әти иде ул: тәрбияле дә, күңелләрен күрә дә белде. Минемчә, андый әтиләр бик сирәк буладыр. Улларының да, кызының да бер генә соравын да җавапсыз калдырмады. Теләсә нинди проблеманы чишү юлын тапты. Авырлыклар килсә, тынычландырды. Без аның белән өч бала тәрбияләдек. Улларыбыз Никита белән Даниил Советлар Союзы Герое исемендәге 1 нче номерлы кадет мәктәбендә укыйлар. Монысы да – әти тәрбиясе.

«Бу хәлләрдән соң фикерләре үзгәрмәдеме соң егетләрнең?» – дип сорыйм.

– Юк. Никитада, киресенчә, ватанпәрвәрлек хисләре көчәйде генә. Әтисе кебек, танк училищесына барырга әзерләнә. Кадет мәктәбендә остазлары – бик көчле кешеләр. Исән чагында Борис Кузнецов та еш килә иде. Олы улым геройларны ишетеп, тыңлап үсте. Даниил әлегә төпле фикергә килмәгәндер дип уйлыйм. Кечерәк чөнки. Ә кызыбыз Екатеринага без, әтиең командировкада, дип кенә әйтеп килдек. Аның да үзенә күрә эше күп. Олимпия резервлары мәктәбендә гимнастика белән шөгыльләнә. Әлегә республика ярышларында призлы урыннар да яулый. Киләчәктә дөнья аренасына чыгарга, Ватанны шулай итеп якларга хыяллана. Балалар әтиләре белән бик горурланалар. Ул – алар өчен үрнәк, чын офицер.

Ярдәмнән ташламыйлар

– Киров һәм Мәскәү районнары хәрби комиссариатына да еш барырга туры килә хәзер. Документлар рәсмиләштереп йөрим. Анда да ярдәм итәргә ашкынып торалар. Мөгамәләләре бик әйбәт. Әле соңгы тапкыр барганда да комиссар Алексей Капотов мине үзе күреп, яныма килде, хәлләремне сорашты. «Алга» отрядында хезмәт иткән егетләрнең бердәмлегенә, кешелекле булуларына сокланам, – ди Марина. – Арада яраланып кайтканнары да бар, ялга да җибәрәләр. Кайткан берсе шалтыратып, хәлләребезне белешеп торалар. Финанс ягыннан да ярдәм итүчеләр булды. Русланны хөрмәт иткәннәре, яратканнары сизелеп тора. Яңарак кайтканнары беренче чиратта каберенең кайда икәнлеген сорашалар, барып кайталар.

10 июнь көнне һәлак булган иремне 18 июньдә Арча зиратында җирләргә дә мөмкин булды, шөкер. Дусты Денис Закиров белән бергә киткәннәр иде. Алып кайту эшләрен егетләр белән бергә барысын да ул оештырды. Монда хәрби комиссариат үз кулына алды. Без бары тик урынын гына күрсәттек.

Улларым укыган кадет мәктәбе дә, кызым шөгыльләнгән Олимпия резервлары мәктәбе дә булдыра алган кадәр ярдәм күрсәтте. Җәйге каникул булуына карамастан, кадетлар, парад киемнәрен киеп, сафка тезелеп, чәчәкләр алып бардылар.

…Руслан гаиләсенә соңгы тапкыр һәлак булырына дүрт көн кала видеодан шалтырата.

– Кәефе шундый әйбәт иде аның. «Менә кепка белән кара күзлек алдым әле. Матурмы?» – дип мактанып та алган булды. Видео аша булса да, соңгы күрешүебез шул булган икән. Безнең күз алдыбызда ул әнә шундый сабыр, батыр, авырлыкларга бирешми, күңелен юктан гына төшерми торган кеше булып калды, – ди Марина.

Белешмә

Руслан ХАННАНОВка 37 яшь була. 2009 елда Казанда Югары танк училищесын тәмамлаганнан соң, Новосибирск өлкәсендә хезмәт итә. 2012 елда армиядән китә һәм Казанда инженер булып эшли.

2022 елның июль аенда махсус хәрби операция барган зонага китәргә карар кыла һәм Татарстанда оештырылган «Алга» батальоны белән контракт төзи. Хәрби операция зонасында хезмәт иткән чорда өлкән лейтенант дәрәҗәсенә күтәрелә. Бу елның февраль аенда «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале белән бүләкләнә.

Апрель аеннан Ханнанов җитәкләгән гранатометчылар взводы Бахмут (Артемовск) янына җибәрелә. Бирелгән заданиене үтәгәндә, командир үзе һәм шәхси состав утырган БМП минага эләгеп шартлый.

Руслан Ханнанов үлгәннән соң Батырлык ордены белән бүләкләнә.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык бишенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кырык бишенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзаларын билгеләп кую турында.
3. Татарстан Республикасы Конституция советы Рәисен билгеләп кую турында.
4. Профессиональ даими нигездә эшләү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын сайлау турында.
5. Татарстан Республикасы һәм Киров өлкәсе арасындагы чик урнашкан урынны билгеләү турында 2023 елның 2 июлендәге 30/177/01/2023 номерлы Татарстан Республикасы һәм Киров өлкәсе арасындагы килешүне раслау хакында.
6. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 450-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 453-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
8. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 446-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 443-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 419-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
11. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 14 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 441-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
12. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 442-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
13. «Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 451-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
14. «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү турында» 436-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
15. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлегє турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 444-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
16. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10^1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 445-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
17. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 435-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
18. «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 440-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
19. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 439-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
20. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 438-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
21. «Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 437-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
22. «Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 452-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
23. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 447-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
24. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 449-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
25. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 82 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.
26. «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 22 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы закон чыгару инициативасы турында.
27. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасын раслау турында.
28. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 368355-8 номерлы федераль закон проекты турында (хәрби бурычлылар белән хезмәт шартнамәсе төзегәндә, шулай ук хәрби исәпкә алу өлкәсе законнарындагы аерым хокук бозулар өчен җаваплылыкны төгәлләштерү өлешендә).
29. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.8 һәм 27.12^1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 379447-8 номерлы федераль закон проекты турында (аерым дару препаратларын кулланганда исерү халәтендә булган йөртүче транспорт чарасы белән идарә иткән өчен административ җаваплылыкны төгәлләштерү өлешендә).
30. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 370147-8 номерлы федераль закон проекты турында (җинаять-үтәтү системасы учреждениеләрендәге яисә вакытлыча тоту изоляторларындагы затларга мобиль элемтә һәм коммуникация чараларын тапшырган өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында).
31. «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 379444-8 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез юридик ярдәм күрсәтү хакындагы законнарны камилләштерү мәсьәләсе буенча).
32. «Россия Федерациясе Урман кодексының 74.1 статьясына үзгәреш кертү турында» 361140-8 номерлы федераль закон проекты хакында (санитария-сәламәтләндерү чараларын билгеләгәндә урман участогын арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр кертү өчен нигезләрне төгәлләштерү өлешендә).
33. «Россия Федерациясе Җир кодексының 39^{10} статьясына үзгәрешләр кертү турында» 361268-8 номерлы федераль закон проекты хакында (чикләрендә гражданнарга җир кишәрлекләрен түләүсез бирү гамәлгә ашырыла торган территорияне билгеләү тәртибен төгәлләштерү өлешендә).
34. «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 21 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чуваш Республикасы Дәүләт Советы закон чыгару инициативасы хакында.
35. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасы халкын транспорт белән тәэмин итү турында».
36. 2023 елның беренче яртыеллыгында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат.
37. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2033-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп вәкаләтләр чоры чикләнмәгән вакытка түбәндәгене сайларга:

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Яңа Савин суд районы буенча:

8 нче суд участогына – Габдрахманов Айдар Рафаэль улын.

2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә сайланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы Габдрахманов Айдар Рафаэль улының вәкаләтләр чоры алдагы вәкаләтләр чоры тәмамланган көннән башлана.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2034-VI ДС

И.И. Гыйлаҗевны Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзасы вазыйфасына билгеләп кую турында

«Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзасы вазыйфасына Гыйлаҗев Илгиз Идрис улын билгеләп куярга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2035-VI ДС

Р.Ф. Гафаровны Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзасы вазыйфасына билгеләп кую турында

«Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзасы вазыйфасына Гафаров Роман Фәһим улын билгеләп куярга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2036-VI ДС

Э.М. Мостафинаны Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзасы вазыйфасына билгеләп кую турында

«Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзасы вазыйфасына Мостафина Эльмира Мәҗит кызын билгеләп куярга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2037-VI ДС

И.И. Гыйлаҗевны Татарстан Республикасы Конституция советы Рәисе вазыйфасына билгеләп кую турында

«Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

Гыйлаҗев Илгиз Идрис улын Татарстан Республикасы Конституция советы Рәисе вазыйфасына билгеләп куярга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2038-VI ДС

ХА-ХА-ХАНӘ

Шушы урында көләсе

Хәтер капчыгыннан

АВЫЛ ХИКМӘТЛӘРЕ

Миндар Әгъләмов мәзәкләрен укыгыз әле, дуслар. Кем соң ул Миндар Әгъләмов диярсез? Әмир авылы егете ул. Әмир исә – Чирмешән районындагы авылларның берсе. Хезмәт сөючән, тырыш, уңган-булган халык яши анда. Мәзәкчән, җор күңелле булулары белән дә тирә-якта шактый ук мәгълүм. Миндар Әгъләмовның Сургутта яши башлавына байтак гомер инде. Әмма ул туган ягы белән элемтәне өзми, игелекле гамәлләре белән дә авылдашларын сөендереп тора, мәзәк хәлләрне дә күңелендә әледән-әле яңарта.

ТӘМЛЕ БОЛТ

Чирмешән районында элек тракторларны Лашман МТСында ремонтлыйлар иде. Ремонтчылар шунда ук туклана да. Өстәл янына утыргач, авылдашыбыз Әхтәм абый кашыклар алырга китә. Шунда иптәшләре, шаярып, аның тәлинкәсенә, бик чиста итеп сөртеп, болт салалар. Әхтәм абый тәмләп кенә ашаганда, шул болт килеп чыкмасынмы?! Ул аш бүлеп торучы Хәтимә апа янына килә дә:

– Хәтимә апа, ашка болтны ни өчен салдың? – ди. Тегесе дә сүзгә кесәгә керә торганнардан түгел:

– Әхтәм энекәш, синең егерме тиенеңә болт салмыйча, трактор салмам бит инде, – дип җавап кайтара.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сез дә авылларыгыз, хезмәттәшләрегез, таныш-белешләрегезгә бәйле кызык-мызыкларны исегезгә төшереп, газета укучылар белән дә уртаклашыгыз әле. Хат-хәбәрләр көтәбез.

КИЕЗ КАТАЛЫ ИНТУРИСТ

Авылдашыбыз Фәрхәтне, хезмәтендә үрнәк буларак, Чехословакиягә туристик путевка белән бүләклиләр. Үзе дә, туганнары да бик шатлана һәм туган-тумача аны бик зурлап чит илгә озата. Бездәге яз ае башлары бу. Бер бажасы: «Бажай! Син инде кеше янында кешечә йөр», – дип тунын кидерә. Икенчесе: «Аягыңа җылырак булыр», – дип киез катасын тәкъдим итә. Өйдәгеләр бүрек, шарф бирә. Берничә көннән Фәрхәтләр төркеме Прагага килеп төшә. Аэропортка килеп керүгә үк Фәрхәт җирле халыкның игътибарын җәлеп итә. «Карагыз әле, аю биетәләрмени, барысының да карашы миңа төбәлгән», – дип зарлана ул иптәшләренә.

Шәһәр исә шау чәчәктә. Җирле халык җиңел киемнән. Авылдан киеп килгән киемнәр тәмам аптырата Фәрхәтне. Кунакханәдә генә калдырыр иде – һәркөнне шәһәрдән шәһәргә күчеп йөриләр, туристлар бит. Җиңелчә кием алыйм дисә – акчасы чамалы. Менә шулай, Фәрхәтебез ундүрт көн дәвамында Чехословакия халкына кәмит күрсәтә. Арып-талчыгып кайта ул сәяхәттән. Кайткач инде тун, киез итек, бүрек, шарф турында ишетергә дә теләми. Шулай да туристлык сәяхәтенә юллама бирүче профсоюз комитетына чиксез рәхмәтле була.

Мач әйткән!

Павел ВОЛЯ, юмор остасы:
Әгәр син нидер эшлисең икән, берни эшләмәүче кешеләр сине шуның өчен генә булса да яратмаячаклар.

«Үпкәсез туй»

«АЛИЯ, АЛИ ТЫ»

Популяр җырчы, буш вакытында бакчада алабута утаучы Айсылу Габдинова да, башка җырчылар сыман, туйларга чыгыштыргалаштыргалый. «Ха-ха-ханә»гә ул кызыклы бер хәл турында сөйләде. Тамадалык эшенә яңа гына керешкән бер алып баручы белән туй эшли болар. «Хөрмәтле Ленар һәм Алия...» дип башлый сүзен алып баручы. «Туктагыз әле, нинди Ленар һәм Алия? Без бит Илназ белән Гөлия туенда!» – тамаданы төзәтеп җибәрәләр. Ул гафу үтенә дә тантаналы нотыгын дәвам иттерә. Тик алга таба тагын шул ук хәл: «Хөрмәтле Ленар белән Алия!..» Кунакларга бу хәл ошамый башлый. Өстәл түрендә утырган Илназ белән Гөлиянең дә йөзләренә әче куна. «Соң менә бит, сценарийда Ленар белән Алия дигән!» – дип әйтеп ташлый тамада. Баксаң, ул сценарийны интернеттан күчереп кенә алган икән һәм кияү белән кәләшнең исемнәрен дә үзгәртергә вакыт тапмаган. Болай булмый! Туй алып баруны җор телле туганнарның берсе үз өстенә ала. Теге тәҗрибәсез тамаданы исә бүгенгә заказдан азат итәләр. Рус әйтмешли, «Алия, али ты» аңар. Шулай итеп, туй алга таба җайлы гына уза. Ә Ленар белән Алия бүген дә матур гына яшәп яталардыр, дип ышанып калыйк. Әй, гафу итегез, Илназ белән Гөлия димәкче идем.

БУГАЙ ТУРЫНДА ҖЫР

Яшел Үзән шәһәренең «Родина» мәдәният сараенда ниндидер тантаналы вакыйга бара. Концерт өлешендә шәһәрнең үзешчәннәре белән бергә Казан артистлары да чыгыш ясый. Тамашачылар күпмилләтле булу сәбәпле, кичәне рус телендә алып баралар. Татар телендәге җырлар бар кешегә дә аңлашылсын дигән уй беләндер инде, алып баручы ир кеше аларның эчтәлегенә кыскача гына русча аңлатма бирә:

– Музыка Гали Ильясова, стихи Гарая Рахима. «Оныттың бугай». Краткое содержание песни: алдынгы колхозларның берсендә «Бугай» кушаматлы пләмәннәй үгез яшәгән, ди. Көннәрдән бер көнне әлеге үгез юкка чыга. Бик озак эзләгәннән соң аны күрше авыл көтүеннән табып алалар. Нәкъ шушы көннән бу ике колхоз туганлашып кала һәм бүген дә дус-тату яшәп яталар. Ә хәзер сезнең игътибарыгызга шушы җырны тәкъдим итәбез. Башкара автор – Татарстанның халык артисты Гали Ильясов.

Шушы сүзләрдән соң сәхнәгә тәгәрәп Гали үзе килеп чыга. Җырның татарча гына түгел, русча куплетларын да башкара. Гадәттәгечә аны халык бик җылы кабул итә һәм җырчының тәрҗемәче-конферанска карата булган үпкәләре дә тамашачыларның көчле алкышлары астында күмелеп кала, онытыла.

Нәҗип БӘДРЕТДИНОВ



Шулай бервакыт Камал театрында

МЕНӘ СИҢА ПЕДРО

Бу хәлне безгә Камал театрының матбугат сәркатибе Илшат Латыйпов сөйләде. Аңар исә – театр тәнкыйтьчесе Нияз Игъламов. Без менә сезгә сөйлибез. Сез дә кемгә дә булса сөйләгәндә, түкми-чәчми җиткерегез, яме. Кыскасы, берзаман Камал артистлары гастрольдән кайтып килә. Мадрид аша! Анда исә Фәрит Бикчәнтәевнең Педро исемле дусты яши икән. Педро русча ярыйсы ук сукалый. Унбишләп татар артистына шәһәр күрсәтергә чыга бу. Бер ресторанга керәләр. «Сез Россиядәнмени?» – ди ресторан хуҗасы һәм кунакларны сыйлый башлый. Өстәлгә кызыл шәраб чыга. Педроның да күңеле була. Тик ап-ак чалбарын зрә кигән ул бу көнне. Шешә авып китә дә кып-кызыл шәраб Педро дускайның ап-ак чалбарына ага. Актерлар аһ итәләр: кайсы тоз сибә, кайсы чүпрәк белән ышкый. Әмма берни эшләп булмый. Ап-ак чалбарлы, дөресрәге, кызыллы-аклы чалбарлы Педро әле тагын ярты көн Камал театры артистларына Мадрид күрсәтеп йөри.

КЕЧЕ ТЕАТР. ӘММА ТАТАРЧА

Камаллыларга гастрольдә төрле театрларда чыгыш ясарга туры килә. Мәскәүнең Кече театрында гел дә бер үк хәл килеп чыга. Беләсез инде, башкалада туристлар күп. Һәм аларның шактые театрга алдан планлаштырып түгел, ә очраклы рәвештә килеп утыра. Берзаман спектакль башланып китә. Актерлар чыга. Һәм татарча сөйләшә башлыйлар. Бер минут уза, ике минут, ун минут.

– Ә кайчан русча сөйләшә башлаячаклар инде? – дип сорый кайбер тамашачылар.

– Бу – татар спектакле, – дигән җавап ишетелә.

– Без бит Малый театрда.

– Әйе, әмма бүген монда татар спектакле куела.

Камаллылар әйтүенчә, мондый хәл даими кабатлана. Һәм алар аңа инде ияләшкән.

Әз-мәз мәзәк

Доклад. Бүгенге эш нәтиҗәләре түбәндәгене күрсәтте: 1) Гарык булдым!

* * *

Минем мәчем британ токымыннан. Аның аша виза алып булмый микән?

* * *

Инде бернинди чыгу юлы калмады дип уйлыйсыз икән, «Титаник» корабы ресторанындагы аквариумдагы кыслаларны күз алдыгызга китерегез.

* * *

Бөтен кеше бары тик дөреслекне генә сөйли башласа, итагатьле кешеләр дөньяда, гомумән, бетәр, дип куркам.

АЕРЫЛМАГЫЗ, АЕРЫЛМАГЫЗ

– Менә әйт әле, синдә берәр яхшы сыйфат бармы?

– Аппетитым яхшы минем.

♥♥♥

– Хатын! Кайчан аяк киеме кия торган кашык алып куясың инде ишек төбенә?

– Менә инде... Туган көнгә дигән сюрприз барып чыкмады.

♥♥♥

Туй белән һәм аерылышу белән, гадәттә, шул бер үк кешеләр котлый. Һәм ике очракта да чын күңелдән.

♥♥♥

– Синең хатын-кыз белән җитди нәрсә булганы бармы соң?

– Бар. Берсендә хәтта судка кадәр барып җиттек.

♥♥♥

Бу дөньяда ирләр булмаса, таза һәм бизәнмәгән хатыннар күбрәк булыр иде.

♥♥♥

Ромашка төнәтмәсе тынычландыра. Әмма аны ирең тондырасы түгел, ә эчәсе.

♥♥♥

Хатын белән мөнәсәбәтләребезне бераз яңартырга уйладык. Стена янында хәзер мин йоклыйм, ул түгел.

♥♥♥

Урамда 30 градус эссе. Әмма матурымның салкын смслары мине суыта.

Психолог кабинетында



– Доктор, соңгы вакытта минем бөтен көчем үземдә көч табуга китә.

* * *

– Мин бик күп ирләрне коткардым.

– Ничек?

– Аларның смсларына җавап бирмичә.

* * *

– Кайвакыт мин үземне Дисней мультфильмнары принцессасы сыман хис итәм.

– Кайдан килә бу хис?

– Янымда төрле хайваннар бөтерелеп йөри.

* * *

Акча әле уйлап чыгарылмаган заманда хатын-кызлар ир-атларның нәрсәләрен яратты икән?

* * *

– Директорыма ультиматум куйдым: йә мин эштән китәм, йә ул миңа хезмәт хакын арттыра.

– Ахыры ничек бетте?

– Компромисс фикергә килдек: мин эштән китмим, ә ул миңа хезмәт хакын арттырмый.

* * *

Тормыш ул йә канат бирә, йә күтеңә тибә. Ике очракта да очасың кебек, әмма хисләре төрлечә.

Хак лайфхак

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5091 данә
Гомуми тираж – 14042 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 300

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+